СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 36 25.02.2016

№ ________ от _________________

# КАРАР

ТР Саба муниципаль районы Советының 2011 елның 26 августындагы 55нче карары белән расланган ТР Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Коррупциягә каршы законнар һәм муниципаль хезмәт турындагы законнар үзгәрүгә, 2015 елның 05 октябрендәге 285-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итү бурычын билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон кабул ителүгә һәм Татарстан Республикасы Саба районы прокуратурасының «Муниципаль хезмәт турында законнарны бозуларны бетерү турында» 2016 елның 20 гыйнварындагы 02-08-04-235-16 номерлы күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 26 августындагы 55нче номерлы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (2012 елның 27 февралендәге 99 номерлы, 2012 елның 26 апрелендәге 118 номерлы, 2013 елның 29 апрелендәге 193 номерлы Совет карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 10.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «10.1. Әлеге Нигезләмәдә мәнфәгатьләр конфликты дигәндә әлеге вазгыять аңлашыла, ул вакытта биләгән вазыйфаны биләүче затның мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрү бурычын күздә тоткан шәхси кызыксынуы (турыдан-туры яисә читләтеп) аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларын (вәкаләтләрне гамәлгә ашыру) тиешенчә, объектив һәм бертуктаусыз үтәвенә йогынты ясый яки йогынты ясый ала»;

1.2. Нигезләмәнең 10.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «10.2. Шәхси кызыксыну дигәндә керемнәр алу мөмкинлеге, шул исәптән мөлкәти хокуклар, мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләр, башкарылган эшләр нәтиҗәләре яисә әлеге Нигезләмәнең 10.1. пунктында күрсәтелгән затның, һәм (яисә) аның белән якын туганда яисә аның белән якын мөнәсәбәттә торучы затның (ата-аналарның, ирләренең яисә хатынның, балаларның, бертуганнарның, сеңелләрнең, шулай ук абыйларының, сеңелләренең, ата-аналарының, балаларының), әлеге Нигезләмәнең 10.1. пунктында күрсәтелгән затның һәм (яисә) аның белән якын мөнәсәбәттә булган затларның (яисә) корпоратив яисә якын мөнәсәбәтләрдә, милек яисә башка мөнәсәбәтләргә бәйле булган гражданнар яисә оешмалар рәвешендә алу мөмкинлеге аңлашыла.».

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш буенча ярдәмчесе Н.Ф.Заһидуллинага барлык муниципаль хезмәткәрләрне әлеге үзгәрешләр белән таныштырырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов